**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Микулино  авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Микулино авылы №117 “13” ноябрь 2018 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы “Микулино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” карары проекты турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Микулино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Микулино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә тулаем төзекләндерү объектларын чисталыкта һәм тәртиптә тотуга бердәм таләпләр билгеләү максатында,

Микулино авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге Советының 2012 елның 11 октябрендәге 59  номерлы Карары (2013 елның 10 сентябрендәге  80 номерлы, 2014 елның 24 февралендәге 93 номерлы, 2014 елның 21 августындагы 116 номерлы, 2017 елның 25 августындагы 59 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Микулино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проектын (1 нче кушымта) хупларга.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге Советының 2012 елның 11 октябрендәге 59  номерлы Карары (2013 елның 10 сентябрендәге  80 номерлы, 2014 елның 24 февралендәге 93 номерлы, 2014 елның 21 августындагы 116 номерлы, 2017 елның 25 августындагы 59 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы

Азнакай муниципаль районының «Микулино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында " гы карары проекты буенча ачык тыңлаулар уздырырга.

3. Билгеләргә:

- уздыру вакыты-2018 елның 26 ноябрьдән 2018 елның 28 декаберенә кадәр;

- үткәрү урыны-Микулино авылы, Совет урамы, 74 йорт ;

– фикер алышына торган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2018 елның 28 декабренә кадәр- Микулино авылы, Совет урамы, 74 йорт, Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге башкарма комитетына (эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр төшке ашка 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр тәнәфес) кертелә ала.

4. Халык тыңлаулары үткәрү буенча түбәндәге составта эшче төркем төзү:

-Такиулин И.Ә. – Микулино авыл җирлеге башлыгы;

-Кучин А.Н. – Микулино авыл җирлеге Советының №5 округы депутаты.

-Кедун М.Н Р.А. – Микулино авыл җирлеге Советының №6 округы депутаты.

5. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге Советының 2012 елның 11 октябрендәге 59 номерлы Карары (2013 елның 10 сентябрендәге 80 номерлы, 2014 елның 24 февралендәге 93 номерлы, 2014 елның 21 августындагы 116 номерлы, 2017 елның 25 августындагы 59 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы "Микулино авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча эшче группага ачык тыңлаулар уздыруны, гражданнар тәкъдимнәрен кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә.

6. Торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссия, ачык тыңлауларда әйтелгән һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, карар проектын эшләп бетерергә һәм чираттагы утырыш каравына кертергә.

7. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http//aznakayevo.tatar.ru. веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән, 2018 елның 19 ноябреннән дә соңга калмыйча халыкка җиткерергә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис: И.Ә.Такиуллин

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Микулино авыл Советының
2018 елның 13 ноябрендәге 116 номерлы карарына1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Микулино авыл җирлеге Советы**

**Микулино авылы №___ __ _________ 2018 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге Советы карары белән расланган 2012 елның 11 октябрендәге 49 номерлы карары (2013 елның 10 сентябрендәге 69 номерлы, 2014 елның 15 июлендәге 99 номерлы, 2014 елның 15 августындагы 106 номерлы, 2017 елның 25 августындагы 59 номерлы карарлары редакциясендә)

2017 елның 29 декабрендәге 463 номерлы Федераль закон нигезендә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының “Микулино авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының "Микулино авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә тулаем төзекләндерү объектларын чисталыкта һәм тәртиптә тотуга бердәм таләпләр билгеләү максатында,

Микулино авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге Советының 12 октябрь 2012 ел, № 49 карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Микулино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә (2013 елның 10 сентябрендәге 69 номерлы, 2014 елның 15 июлендәге 99 номерлы, 2014 елның 15 августындагы 106 номерлы, 2017 елның 25 августындагы 59 номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.5 пунктының икенче, өченче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Территорияне төзекләндерү - гражданнарның яшәү шартларын тәэмин итүгә һәм яхшыртуга, муниципаль берәмлек территориясенең санитар һәм эстетик торышын яхшыртуга, торак пунктлар территорияләрен һәм мондый территорияләрдә урнашкан объектларны, шул исәптән гомуми файдаланудагы территорияләрне, җир кишәрлекләрен, биналарны, төзелмәләрне, корылмаларны карап тотуга юнәлтелгән әлеге Кагыйдәләр белән билгеләнгән чаралар комплексын гамәлгә ашыру эшчәнлеге.

Төзекләндерү элементлары-декоратив, техник, планлаштыру, конструктив җайланмалар, яшелләндерү элементлары, җиһазларның һәм бизәлешнең төрле төрләре, шул исәптән биналарның фасадлары, төзелмәләр, корылмалар, кече архитектура формалары, стандарт булмаган корылмалар, мәгълүмат щитлары һәм территорияне төзекләндерүнең состав өлеше буларак кулланыла торган күрсәткечләр.».

1.2. Түбәндәге эчтәлекле 2.10.3.1 пунктын өстәргә:

«2.10.3.1.Йорт тамгаларындагы , тышкы мәгълүмат чараларында мәгълүмат Россия Федерациясе дәүләт теле һәм Татарстан Республикасы дәүләт телләре турындагы закон таләпләрен үтәү белән урнаштырылырга тиеш. Ике һәм аннан да күбрәк тел куллану очрагында текстлар эчтәлеге һәм техник бизәлеше буенча охшаш , дөрес һәм аңлаешлы итеп эшләнгән булырга тиеш.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http//aznakayevo.tatar.ru. веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.